**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

"27" ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлыТатарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:
1.Мирная урамында газүткәргечнең электр-химик яклау КИПын(контроль-үлчәү пунктын) урам уртасыннан урам читенә күчерү - проектын төзү, КИП күчерү буенча монтаж эшләре һәм хезмәт өчен түләү;
2) Асфальт катламын ремонтлау:
- Киров урамындагы 58 - нче номерлы йорттан 34-нче номерлы йортка кадәр асфальт юлдагы чокырларны ремонтлау, материаллар сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү;
3) Коеларны төзекләндерү :
- Яшьләр урамындагы 28нче һәм 51-нче номерлы йортлар янындагы коеларны ремонтлау, койма белән әйләндереп алу очен төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;
4) Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:
-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу, урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;
5) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту.
- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Салахов И.И.

Совет Куныерского сельского поселения
Күнгәр авыл җирлеге советы
ИНН 1610000797
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ * ОГРН1031639800213